ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 август, 2020 ел № 41/8

Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы Карары, «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы Карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2018 елның 10 августындагы 26/8 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10, 2009 елның 23 маендагы 31/6, 2019 елның 6 декабрендәге 34/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә;

- 68 пунктның 3 пунктчасында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 74 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«74. Тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр аерым белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренә бирелә.»;

- 75 пунктта «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 76 пунктның беренче абзацында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 78 пунктның 15 нче таблицасы исемендә «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 1 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 58 пунктча белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «58 | «Мәгариф отличнигы» билгесе. |

2) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә;
- 12 пунктның беренче абзацында «беренче - икенче төркем белән» сүзләрен «бер-ике төркем белән» сүзләренә алыштырырга;
- 32 пунктта түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар өчен ике яшь төркемнәрендә, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч яшь төркемнәрендә хезмәт күрсәткән педагогик хезмәткәрләрнең һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары үз көченә кергәнче түләнә торган күләмдә, хезмәтнең катлаулылыгын исәпкә алып башкарыла.»;
- 1 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 58 пунктча белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «58. | «Мәгариф отличнигы» билгесе. |

2. Шәһәр Советының «Физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 8 ноябрендәге 27/9 номерлы карарына (Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6, 2019 елның 23 маендагы 31/6 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 55.1 пунктында «Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «Башкарма комитет тарафыннан расланган эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары нигезендә.» сүзләренә алмаштырырга.

3. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары һәм Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Яр Чаллы шәһәре муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә 71 пунктның 25 таблицасына түбәндәге эчтәлекле 2.13 пунктча өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.13. | Физкультура-спорт оешмасы инструктор-методисты | икенче | 50»; |

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

1.